**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1023**
**16.02.2023**

Башкарма комитетның 2022 елның 9 августындагы 4005 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә велопарковкалар, велосипедларны, роликларны, самокатларны һәм башка спорт инвентарен прокатка бирү пунктлары урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштырылырга мөмкин булган объект төрләренең исемлеген раслау турында» 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар, җәмагать сервитуты билгеләмичә, төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә велопарковкалар, велосипедларны, роликларны, самокатларны һәм башка спорт инвентарен прокатка бирү пунктлары урнаштыру схемасын эшләү комиссиясенең 2022 елның 22 декабрендәге 1 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 9 августындагы 4005 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә велопарковкалар, велосипедларны, роликларны, самокатларны һәм башка спорт инвентарен прокатка бирү пунктлары урнаштыру схемасына (алга таба – Схема), кушымта нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә велопарковкалар, велосипедларны, роликларны, самокатларны һәм башка спорт инвентарен прокатка бирү пунктлары урнаштыру урынын кертеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 16 февралендәге
1023 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында (http://nabchelny.ru/company/1907) урнаштырылган
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә велопарковкалар, велосипедларны, роликларны, самокатларны һәм башка спорт инвентарен прокатка бирү пунктларын урнаштыру схемасына кертелергә тиешле спорт инвентарен прокатка бирү пунктларын урнаштыру урыннарының
исемлеге

| № | Объектның урнашу урыны | Объектның мәйданы, кв.м | Объектның төре | Объектның урнашу урыны координаталары |
|---|---|---|---|---|
| Үзәк районы | | | | |
| 20.1 | Раскольников урамы һәм Х. Туфан проспекты кисешкән урында | 84 | Электр транспорт чараларыннан тыш, спорт инвентарен прокатка бирү пункты | 471114,44 2321359,03<br>471112,00 2321367,70<br>471116,81 2321369,06<br>471115,18 2321374,84<br>471106,90 2321372,49<br>471110,97 2321358,05<br>471114,44 2321359,03 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева